КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 25 декабрь г.Казань № 1220

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәтен оештыру турында» 2017 ел, 21 апрель, 234 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәтен оештыру турында» 2017 ел, 21 апрель, 234 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 7 август, 642 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәте багланышларын тәэмин итү буенча координация советы турында нигезләмәдә:

4.4 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәте багланышларын тәэмин итү буенча координация советы составында

Координация совет составыннан Р.М.Гарифуллинны, Л.Ю.Глухованы, А.М.Сибагатуллинны, А.Ю.Петуховны, Р.Җ.Хәбибуллинны чыгарырга;

Координация совет составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызын | Татарстан Республикасы мәдәният министрын |

| | |
|---|---|
| Заһидуллин Рөстәм Илдус улын | Татарстан Республикасы юстиция министрын |
| Сөләйманов Тимур Җәүдәт улын | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре буенча министрының беренче урынбасарын |
| Суржко Николай Владимировичны | Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны; |

В.А.Леонов вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Татарстан Республикасы спорт министры»;
Д.И.Фәттахов вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Татарстан Республикасы яшьләр эшләре буенча министры, Координация советы рәисе урынбасары»;
В.В.Шихобалов вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Татарстан Республикасының Яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин